ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**14 февраль 2024 ел** **№ 90**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 октябрендәге 32 нче номерлы «Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге бюджет процессы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 октябрендәге 32 нче номерлы карары белән расланган (2021 елның 13 декаберендәге 37 нче номерлы Совет карары редакциясендә) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 14 статьяның 1 пунктындагы 3 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 19 статьяның 1 пунктында «һәм аларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга

1.3. 20 статьяның 3 пунктының 2 абзацында «билгеләнгән срокларда» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 20 статьяның 3 пунктындагы 3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль программалар бюджет турындагы карарга агымдагы финанс елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча туры китерелергә тиеш.»;

1.5. 20 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә җирле бюджет чыгымнарының тиешле һәр программасы буенча җирле бюджет турындагы карар белән раслана.»;

1.6. «Ведомство максатчан программалары» 21 статьяны үз көчен югалткан

дип танырга;

1.7. 46 статьяның 1 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2) җирле бюджеттан физик затларга гавами норматив йөкләмәләрне һәм башка түләүләр буенча йөкләмәләрне үтәүне тикшереп тору, муниципаль мөлкәт белән идарә иткәндә һәм (яисә) аннан файдаланганда җирле бюджеттан керемнәр булдыру һәм аны гамәлгә ашыру, шулай ук җирле бюджеттан, муниципаль контрактлардан акчалар бирү турындагы шартнамәләрнең (килешүләрнең) шартларын үтәүне тикшереп тору;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адрес буенча интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов